**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 30 сентябрендәге 4087 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы**
**«Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон белән Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 апрелендәге 1242 номерлы, 2024 елның 14 маендагы 2005 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.2.1. пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктчаны «башка зат белән шартнамә төзелгән» сүзләреннән соң «яки, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, күрсәтелгән карар кабул ителгән» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 9 пунктчаны «башка зат белән шартнамә төзелгән» сүзләреннән соң «яки, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән

очракта, күрсәтелгән карар кабул ителгән» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3. 10 пунктчаны «җир кишәрлегеннән ясалган» сүзләреннән соң «яки, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, үзенә карата күрсәтелгән карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**